**3 номерлы КАРАР**
**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Тәмте- Мәтәскә торак пунктының гражданнар җыены буенча**

**2019 елның 6 декабре Тәмте-Мәтәскә авылы**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Мәтәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,2019 елның 6 декабрендә Тәмте- Мәтәскә торак пунктында узган гражданнар җыенының тавыш бирү нәтиҗәләре белән хисап комиссиясе беркетмәсе төзелде, «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Тәмте- Мәтәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2020 елда гражданнарның 700 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:
- юлларны кардан чистарту;
-су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (башняны коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу , чишмәне төзекләндерү өчен түләү килешү буенча);
- янгын гидранты өчен колонка сатып алу һәм урнаштыру

« РИЗА» «КАРШЫ»?».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында хисап комиссиясе беркетмәсе нигезендә:

Җыенда катнашучыларның сайлау хокукына ия булучылары исемлегенә 56 кеше кертелгән;
җыенда катнашучыларның тавыш бирүчеләре саны 42 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәгеләр билгеләнде:
гражданнар җыенында катнашкан 42 кеше «Риза» позициясе өчен тавыш бирде;
«Каршы» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Тәмте-Мәтәскә торак пунктында гражданнар җыены булып узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2.Мәсьәлә буенча карар кабул итәргә: «Сез ризамы, Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең Тәмте- Мәтәскә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган

кешедән 2020 елда гражданнарның 700 сум күләмендә үзара салымын кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны чираттагы эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

- юлларны кардан чистарту;

-су белән тәэмин итү системасын ремонтлау (башняны коймалау өчен төзелеш материаллары сатып алу , чишмәне төзекләндерү өчен түләү килешү буенча);

- янгын гидранты өчен колонка сатып алу һәм урнаштыру-кабул ителгән.

3. Җыен нәтиҗәләре турында әлеге карарны, гамәлдәге законнар нигезендә, шул исәптән, мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Олы Мәтәскә авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәтәскә авыл җирлеге Башлыгы: М. А. Вәлиуллин